وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

6+


# Дин вә Мәгыйшәт

№13 (156). 28 сентябрь 2012 / 12-зөлкагдә-1433

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



Ислам Совет дәүләте сәясәтендә (1943-1948 еллар) ▷2,4◁



Ходай Үзе көч бирә ▷3◁

Ярминкәләрдә – хәләл ризыклар ▷4◁

# Өлкәннәрне хөрмәт итик!

## Аллаһы Сүбханәһү вә Тәгаләгә мактауларыбыз булса иде! Әссәламегаләйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәракәтүһү!

**Әссәламегаләйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәракәтүһү! Өлкән буын вәкилләрен чын күңелдән якынлашып килүче Өлкәннәр көне белән котлыйм!**

Әбиләребез, бабайларыбыз күп газаплар-авырлыклар күреп, зур тормыш тәҗрибәсе туплаган, без яхшы тормышта яшәсен өчен җәмгыятебезгә бик күп хезмәт иткән кешеләр - зур хөрмәткә лаеклы өлкәннәр. Аларга сугыш елларында илне сакларга һәм сугыштан соң илне аякка бастыру чорында, аннары да төрле каршылыкларны җиңеп, зур сынаулар аша узарга туры килгән. Бүгенге замананың да төрле авырлыклары олы буынны читләтеп узмый.

Хәзерге көндә динебезне таратуга, республикабызда бер-бер артлы мәчетләр ачылуга зур өлеш керткән, милләтебезне иманлы итәргә тырышкан дин әһелләренең күп өлешен олы ихтирамга лаек өлкән яшьтәге муллалар тәшкил итә. Алар безнең өчен остазлар, мөгаллимнәр. Күпләребез нәкъ менә авылларга иман нуры бирергә тырышкан татар бабайларының, ак яулыклы әбиләребезнең нәсыйхәтләрен, вәгазьләрен тыңлап Аллаһы Тәгалә юлына басты; алар бәндәләрне иманга, туры юлга чакырып яши.

Өлкәннәрнең мәрхәмәте, тәҗрибәсе, беркайчан да өметләрен, сабырлыкларын югалтмыйча бары яхшылыкка омтылып яшәүләре яшь буын өчен зур үрнәк.

Олы кешеләрне, иң беренче чиратта, үзеңнең олыгайган әти-әниеңне, туган-тумачаларыңны, күршеләреңне, юлыңда очраган өлкәннәрне ихтирам итсәң, игътибарлылык күрсәтсәң, әлбәттә, Аллаһы Тәгалә синең дәрәҗәңне күтәрер. Гали (рг) яһүди картына ихтирамлылык күрсәткәнгә күрә, Аллаһы Тәгалә аны да зурлады. Әҗер-савап алсын өчен иртәнге намазда пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) янына Җәбраил фәрештәне җибәреп, рөкүгътан билен турайтмыйча, аны озак кына торгызды һәм Гали (рг) килеп кушылгач кына, намазын дәвам иттертте. Ни өчен болай эшләдең дигәч, ул: "Яһүди картын узып китеп, аңарга аркам белән китеп, артымны күрсәтеп китмәс өчен", - диде. Шулай эшләү бәрабәренә, Аллаһы Тәгалә аны хөрмәтләде.


Аерым бер көннәрдә генә түгел, һәрдаим өлкәннәребезне хөрмәт итәргә насыйп итсен. Чөнки безнең дә олыгаясыбыз бар, килер бер көн, без дә алар кебек картаербыз. Безне дә яшь буын ихтирам итсен өчен, Аллаһы Тәгалә безгә башка бәндәләрен ихтирам иттерсен өчен, пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) сөннәтен үтәп, өлкәннәребезгә хәер-хөрмәт күрсәтеп яшәргә тиеш. Безнең өлкәннәргә карата яхшы мөнәсәбәт - ул үзебездән соң килгән буынны тәрбияләү, аларны тәүфыйклы итү.

Аллаһы Сүбханәһү вә Тәгалә Үзенең рәхим-шәфкатеннән ташламаса иде! Өлкәннәргә балалар, оныклар ярдәмен тоеп, җан тынычлыгы табып, урыннары өйләренең түрендә булып, кадер-хөрмәттә яшәргә язса иде!

*Үзәкләшкән дини оешма –*
*ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе,*
*мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ*

# Хәнәфи мәзһәбендәге мөселманнарның хаҗ кылу тәртибе

**Хаҗ кылу - ислам дине баганаларының берсе. Шул сәбәпле ул сау-сәламәт, балигъ, үз акылында һәм ирекле, юл чыгымнарын күтәрерлек матди мөмкинлеге булган, үзе хаҗда вакытта гаиләсе башка барлык яшәү чыгымнарын капларлык мөһим мохтаҗлыклардан азат очракта һәр мөселманның бурычы (фарыз гамәл). Бу бурычны, үз гомереңдә бер тапкыр булса да үтәү зарур.**



Ибне Мәҗаһ тарафыннан китерелгән, Пәйгамбәребезнең (сгв) бер хәдисе моңа дәлил булып тора. Әлеге хәдистә болай дип әйтелә: "Пәйгамбәрдән (сгв) аның бер сәхабәсе сораган: "Аллаһның Илчесе, хаҗ кылу ел саен үтәлергә тиешме, әллә гомергә бер тапкырмы?" Аңа Аллаһның Рәсүле (сгв): "Бер тапкыр гына, тик кемнең мөмкинлеге бар, аңа (күбрәк тә) мөмкин", - дип җавап биргән.

Хаҗ шартларына, бер үк вакытта, сәфәрнең куркынычсыз булуы да керә. Хатын-кызга, гәрчә ул өлкән яшькә җиткән булса да, мәхрәмнән (ир бертуганы, атасы, әтисенең яки әнисенең ир-ат бертуганы, кызының ире) яки иреннән башка хаҗ кылу - карәхәт-тәхрим (инкяр ителә торган, хәрамгә якын гамәл) дип санала; әмма ул, шулай да, алардан тыш хаҗ кыла икән - аның бу бурычы башкарылган булып исәпләнә. Әгәр дә үсмер, ихрамга кергәч кенә (микатта хаҗ кылу нияте) балигъ булса, һәм дә, аннан соң Гарәфәт тавында басып торганчы ихрамын яңартырга микатка кайтып килмәсә, бу гамәл аның өчен мәслихәт, тик киләчәктә хаҗ кылу бурычын аннан төшерми.

Мәккәгә Мәдинә ягыннан сәфәр кылучыларга (Россиядән сәфәр кылучылар шул юлдан килә) микат булып Мәдинәдән алты миль, Мәккәдән ун мәрхәл (400 чакрымнан артык) булган Зөл-Хөләйфә дип аталган урын исәпләнә. Хәзерге вакытта бу урын Әбу Гали исеме астында да билгеле. Кем хаҗ яки гомрә кылырга ниятләсә, шушы микатта яки аннан алдарак ихрамга керә.

Ихрамга кергәнче барысына да, шул исәптән, хәтта бала тапканнан соң чистарыну (нифас) һәм хәез (айлык күремнәр) халәтендәге хатын-кызларга да госел коену кирәк.

Ирләр ике ак тукыма кисәген кияләр, аларның яңа булуы яхшы, әмма чиста һәм юылган булсалар да ярый. Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллә-ллаһу галәйһи үә сәләм әйткән: "Киемнәрегезнең иң яхшысы - ак киемдер, шуңа да аның белән мәрхүмнәрегезне төрегез һәм дә үзегез дә шундыйны киегез" (Ибне Мәҗаһ).

Тукыманың бер кисәге белән кендектән башлап, тезгә кадәр тәнне уратып алалар. Киемнең бу өлешен

*(Ахыры 3 нче биттә.)*

## ЯҢАЛЫКЛАР

**КАЗАНДА СПОРТ ЯРЫШЛАРЫ ҮТТЕ**

**22 сентябрь көнне ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең "Алтын урта" татар-мөселман яшьләре җәмгыяте мәдрәсә шәкертләре арасында "Сәламәтлек көне" уздырды.** Чара Казанның 51 нче мәктәбе янындагы спорт мәйданында үткәрелде. Коръән укып башланган чарада Карьер бистәсендәге Котдус мәчетенең имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин вәгазь сөйләде. Кызлар өчен ярышларны Россия ислам университетының өлкән укытучысы Е.Ратова, ә егетләргә Россиянең һәм Татарстанның физик культура һәм спорт отличнигы Р.Мифтахов оештырды.

Ярышларда катнашучыларга мөфти Илдус хәзрәт Фәиз исеменнән истәлекле бүләкләр тапшырылды. Бәйгеләрдә Казан ислам колледжы шәкертләре зур активлык күрсәтте.

**ДӘҮЛӘТ ДУМАСЫ ҖӘЗАНЫ КАТЫЛАЙТУ ТӘКЪДИМЕ БЕЛӘН ЧЫКТЫ**

**РФ Дәүләт Думасына дин тотучыларның хисләрен рәнҗеткән һәм изге урыннарны мәсхәрәләгән өчен җәза бирергә тәкъдим итә торган закон проекты керде.** Бу турыда "Интерфакс" хәбәр итә.

Мондый җинаять өчен иң зур җәза итеп өч елга кадәр иректән мәхрүм итү күздә тотыла. Шулай ук 300 мең сумга кадәр штраф яки 200 сәгатькә кадәр мәҗбүри эш кушылырга мөмкин.

Ә биналарны (һәйкәлләрне) мәсхәрәләгән яки җимергән өчен 500 мең сумга кадәр штраф яки 5 елга кадәр иректән мәхрүм ителү каралган.

Моннан тыш, административ хокук бозулар турындагы Кодекска үзгәрешләр кертелергә мөмкин. Халык алдында дини әдәбиятны, тамгаларны (билгеләрне) һәм эмблемаларны мәсхәрәләгән яки бозган өчен 30 меңнән 50 меңгә кадәр штраф билгеләнәчәк.

Шунысын да билгеләп үтик: Думадагы дүрт фракция дә дин тотучыларның хисләрен рәнҗеткән өчен җәзаны катылайту тәкъдиме белән чыкты.

**ИСЛАМ КОЛЛЕДЖЫНДА АЧЫК ДӘРЕС УЗДЫ**

**27 сентябрь көнне Мәрҗани мәчетенең конференц-залында Казан ислам колледжының барлык курслары өчен дә "Ислам - тынычлык һәм сабырлык дине" дигән темага ачык дәрес үтте.** Дәресне Казан ислам колледжы директоры урынбасары Нияз хәзрәт Сабиров үткәрде. Ул ислам диненең нигезе һәм аның төп үзенчәлекләре турында сөйләде, сабырлык турында тарихи мисаллар китерде. Бу чарада шулай ук колледж укытучысы Сабир хәзрәт Грижак чыгыш ясады. Ул жентекләп "җиһад" төшенчәсен аңлатты һәм һәр мөселманның беренче урындагы бурычы булып, үз-үзе белән, үзенең рухи кичерешләре, кимчелекләре белән җиһад кылырга тиешлеген ассызыклап үтте. Дәрес ахырында Коръән укытучысы Баһадир хәзрәт Алиев кеше хокуклары турында нәшид башкарды.

**ГАЗЕТАЛАРГА ЯЗЫЛЫРГА ОНЫТМЫЙК!**

**1 сентябрьдән 2013 елның I яртыеллыгы өчен "Дин вә мәгыйшәт" (язылу индексы - 16046) һәм "Умма" (83072) газеталарына язылу башланды. 6 айга язылу бәясе - 118,38 сум.**

## Азнакай һәм Чирмешән муллалары нәзарәткә җыелды

**26 сентябрь көнне Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтендә Азнакай һәм Чирмешән районнары дин әһелләренә имам-хатыйблык вазифасын раслаучы шәһадәтнамәләр бирелде. Шәһадәтнамәләрне мөфтинең беренче урынбасары Габдулла хәзрәт Әдһәмов тапшырды. Чарада әлеге ике районның мөхтәсибләре һәм авыллардан килгән иллегә якын имам катнашты.**

Дога укып башланган шәһадәтнамә тапшыру тантанасында Габдулла хәзрәт Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең эшчәнлеге турында сөйләде, имам-хатыйблык вазифасы нечкәлекләрен җиткерде. "Имамнарның дин юлындагы эшчәнлеге саваплы һәм шул ук вакытта бик җаваплы. Бу хакта күп сандагы хәдисләребездә әйтелә. "Сезнең арадан иң күркәме кем? Үзе өйрәнеп, башкаларга өйрәтүче", - диелә хәдистә. Безгә менә шушы динебезне тарату, динебез ярдәмендә җәмгыятебезне начарлыклардан дәвалау вазифасы йөкләнгән. Һәркайсыбыз, авылларда Диния нәзарәтенең бер вәкиле. Үзара бердәм булып, динебез кыйммәтләрен халыкка өйрәтеп яшик", - диде ул.

Вәгазь тыңлаганнан соң муллаларга шәһадәтнамәләр тапшырылды һәм Коръәннең Казан басмасы бүләк итеп бирелде. Изге Китапны тапшырганда Габдулла хәзрәт кыскача Казан басмасы тарихы белән таныштырып узды.

Азнакай мөхтәсибе Әмирҗан хәзрәт Якупов сүзләренә караганда, районда бүгенге көндә 39 мәчет эшләп килә. Һәр мәчеттә диярлек дини белем бирү курслары оештырылган. "Без Казанга килеп шәһадәтнамәләр алуны көтеп алдык. Аларны сөенеп кабул иттек. Шәһадәтнамә алу халык алдында дәрәҗәбезне, хөрмәтебезне арттыра, үзебезнең дә күңелләрне үсендереп җибәрә. Алга таба да шушы шәһадәтнамәләр биргән вазифаны тырышып үтәп, үрнәк күрсәтеп, авылдашларыбызга яхшы нәсыйхәтләр биреп эшләргә язсын. Нәзарәткә бүләкләр өчен дә, менә шушылай барыбызны җыйганы өчен дә рәхмәт", - диде ул.



## Таможня вәкилләре хаҗ сәфәрен оештыручылар белән очрашты

**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтендә республиканың таможня вәкилләре һәм быел хаҗ сәфәрен оештыручылар катнашында киңәшмә үткәрелде.**

Чарада Татарстан таможнясы җитәкчесенең беренче урынбасары, таможня хезмәте полковнигы Максим Чмора, "Казан Аэропорт"ының махсус таможня үтү бүлеге башлыгы Вячеслав Ким, нәзарәтнең халыкара мөнәсәбәтләр бүлеге белгече Габдулла хәзрәт Галиев, табиб Рамил Хисамов һәм "ДУМ РТ ХАДЖ" программасы буенча хаҗга баручыларның төркем җитәкчеләре катнашты.

Таможня хезмәте полковнигы Максим Чмора очрашуда таможня үтү тәртипләре белән таныштырды. Шулай ук ул узган еллар тәҗрибәсеннән чыгып киңәшләрен бирде. "Оештыру моментлары бик мөһим, чөнки барыбыз өчен дә хаҗ сәфәренең проблемаларсыз яхшы үтүе әһәмиятле. Хаҗ сәфәренең әйбәт үтүе оештыручыларның да, аэропортның, башка транспорт оешмаларының, шул исәптән дәүләт органнарының да уңай имиджын тудыра. Ел саен Президент каршындагы Хаҗ буенча совет хаҗ сәфәренең ничек үткәрелүен бәяли. Төрле операторлар, аэропортлар эшчәнлеге тикшерелә. Барысы да үзебездән тора, иң мөһиме оештыру сыйфатлы булырга тиеш", - диде. Вячеслав Ким исә хаҗ кылырга ниятләгән һәркемне хөрмәт итүләрен ассызыклады, таможня узганда тикшерүләрнең закон нигезендә алып барылуын билгеләп үтте.

Максим Чмора хаҗга җыенучыларга көчле психотроп дарулар, чит илдә, матурлыгына кызыгып, кыйммәтле сувенерлар алудан тыелырга, шулай ук бизнес белән изге сәфәрне бутамаска киңәш итте. "Хаҗдан 50 литр ак әнис мае яки күп санда спиртсыз хушбуйлар алып кайтырга тырышучылар да бар. Чит илдә алынган товар бары тик шәхси файдалану өчен генә булырга тиеш. Бер үк төрле товар күп санда алынган икән, ул инде коммерция өчен дигән сүз. Хаҗга баручыларга кулларына 10 мең доллар күләмендә акча алу рөхсәт ителә. Авиация транспортында чит илдә алынган һәм декларация үтмәгән товарның авырлыгы 50 килограммнан һәм бәясе 10 мең евродан артмаска тиеш". Моннан тыш Максим Владимирович чит илләрдә шик тудырырлык китаплар алмаска, тыелган басмалардан сак булырга чакырды.

Хаҗга баручыларның төркем җитәкчеләре, үз чиратында, таможня таләпләрен хаҗиларга җиткерәчәк.

## Традицион ислам мөселманны буйсынучан һәм тыңлаучан булырга өнди

**"Традицион ислам" - ул үзбилгеләмә түгел, ә бүген килеп туган ситуацияне хәл итү өчен бирелгән атама, төгәлләнмәгән доктрина, тренд.**

Мәсәлән, Әбу Хәнифә үз заманында, фарсыларны Исламнан аермас өчен, диндә шәраб эчү генә хәрам, дип әйтеп, фарсыларның традицион эчемлеге булган исерткечтән - набиздан аларны тыймаган. Ахырдан дин юлына ныклап баскач, алар үзләре үк хәмердән баш тарткан. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) яшәгән чорда ук та фарсылар намазны үз телләрендә укыган. Аларга сүз әйтмәгәннәр. Традицион ислам - ул китап сүзен генә түгел, реаль тормыш ситуациясен, яшәү җирлеген исәпкә алып гамәл кылуны күздә тота. Формальлек һәм хәрефчелеккә бирелеп, һәр нәрсәне туры мәгънәсендә аңлаучыларның бүген гарәп илләрендә әүлияләрнең каберләрен җимерүләрен, тарихи һәйкәлләрне юк итүләрен күрәбез бит. Ә тарихи һәйкәлләр белән бергә традицияләр, буыннан-буынга күчеп килгән йолалар да юкка чыга. Безгә башбаштаклыкны, мин-минлекне бетерергә, сыгылмалырак булырга кирәк. Төркиядә, тормыш тәҗрибәсе туплап, җитәрлек гыйлем эстәп, кырык яшенә җитмәгән ир-атларны "бары тик чәй ясарга гына сәләтле" диләр. Традицион ислам мөселманны буйсынучан һәм тыңлаучан булырга өнди.

Бер авылның надан мулласы халыкка аякларын юмыйча гына мәчеттә намаз укырга рөхсәт биреп, авылдашларын мәчеткә йөрергә өйрәтә. Ә авылга килгән гыйлемле шәкерт, бу хәлне күреп, мулланы тәнкыйтьли башлагач, ул: "Мин аларны мәчеткә йөрергә өйрәттем, ә хәзер син аларны аякларын юарга өйрәт", - ди. Без ике начарлыкның азрак зыян китерә торганын сайларга тиеш.

***Рөстәм хәзрәт БАТЫР,***
***ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Голамәләр шурасы рәисе***

# *Ислам Совет дәүләте сәясәтендә (1943-1948 еллар)*

**Сугыш дәүләтнең Исламга карата мөнәсәбәтенә сизелерлек төзәтмәләр кертә. Хөкүмәт дингә элеккечә тыелгысыз басым ясау тәҗрибәсеннән баш тартып, илнең диндар халкына өлешчә ташламалар ясарга мәҗбүр була.**

Дин белән дәүләтнең кискен капма-каршылыгы дәвам ителгән очракта, хезмәт тылында таркалу килеп чыгу ихтималлыгы туа һәм хакимиятне, буйсындырырга тырышылган, тик рухы сындырылмаган динле халыкның ышанычын югалта баруы куркыта. Хөкүмәт үзенең сугышчан дәһрилек сәясәтен авызлыкларга, аны Исламга карата түземлерәк мөнәсәбәткә алыштырырга мәҗбүр була. 1943 елдан хакимият дингә карата юл кую сәясәтенә күчә.

СССР Халык комиссарлары Советының 1944 ел, 19 май Карары белән СССР Халык комиссарлары Советы каршында Дин эшләре буенча Совет оештырыла. Ул православиедән тыш, бар конфессия дини оешмалары берләшмәләре җитәкчеләре һәм хөкүмәт арасында бәйләнешләр өчен җавап бирергә тиеш була.

Шунысын әйтеп китәргә кирәк, тикшерүчеләр, кагыйдә буларак, сугыш вакыты дини сәясәтендәге сизелерлек бу борылышны ил өчен авыр булган ул көннәрдә дини оешмаларның, аның эшлеклеләренең ватанпәрвәрлек карашларын куәтләүләре белән бәйлиләр. Ислам тәгълиматының танылган белгече Т.С. Сәидбаев, мәсәлән, бу күренешкә карата гомум кабул ителгән карашларны берләштереп: "... Совет хакимиятенә карата лояль бу карашлар, аларның эшчәнлекләрендә узган гасырның 20 нче елларыннан ук урын алып, индустрилизация, социализм төзү вакытында тагын да үскән һәм ныгыган карашларның логик йомгаклануы булды", - дип исәпли.

Чынлап та, сугыш елларында мәчетләрдә Ватанны якларга чакырулар яңгырый, фронтка киемнәр, ашамлыклар җыю оештырыла, дәүләт облигацияләре займнары таратыла, мөселманнар Кызыл Армиягә акча җыюда катнашалар.

СССР мөселманнары танк колоннасы төзү өчен акча җыялар, бу турыда мөселманнарның Үзәк Диния нәзарәте рәисе, мөфти Г.Рәсүлев телеграмма белән Сталинга хәбәр итә. Мөфтинең телеграммасы һәм аңа җавап "Известия" газетасында басылып чыга.

1942 нче елның май аенда ук СССРның Европа өлеше һәм Себер мөселманнары Үзәк Диния нәзарәтенең чираттан тыш киңәшмәсе үтә. Анда СССРның бар мөселманнарына гомерләрен кызганмый Ватанны яклау турында мөрәҗәгать кабул ителә. Ул бар мәчетләрдә дә, мөселманнарның җыелышларында да укыла.

Нәкъ менә шул мөрәҗәгать һәм динле кешеләрнең аңа карата булган фикерләре хөкүмәтне мөселманнарның лояльлегенә инандыра, һәм шуның нәтиҗәсе буларак, Исламга карата Бөек Ватан сугышы елларында дини сәясәттә борылыш күзәтелә. Мөселманнарның Үзәк Диния нәзарәте мөрәҗәгате дингә мөнәсәбәт курсы үзгәрүнең тышкы бер сәбәбе була. Чынбарлыкта исә, дингә һәм дин тотучыларга карата мөнәсәбәт үзгәрүнең төп сәбәбе - СССРда динне җиңеп чыгу турындагы фикерләрнең иллюзор булуын, чиркәү белән мөнәсәбәтләрне нормальләштерү, гәрчә күз буяр өчен генә булса да, нормальләштерү зарурлыгын аңлау була.

Хакимиятнең дингә карата сугыш елларында булган чагыштырмача лояль сәясәте, аның дин эшлеклеләренә бирелгән кайбер салым ташламалары гамәли гәүдәләнеш ала. Аларның берсе СССР Халык комиссарлары Советы каршындагы мобилизациядән азат итү һәм кичектерү буенча комиссия тарафыннан 1945 елның 26 февралендә кабул ителгән карарында билгеләнгән. Бу карар буенча, гыйбадәт йортларында дини йолаларны башкаручы дин эшлеклеләре хәрби хезмәткә чакырылудан азат ителергә тиешләр. Бу - СССР территориясендә эшчәнлек алып барган барлык конфессия руханиларына да кагылган.


*(Ахыры 4 нче биттә.)*



2012 ЕЛ - ТАТАРСТАНДА КОРЪӘН ЕЛЫ

# Коръәндәге риторик дәлилләр

*(Ахыры. Башы газетабызның 21 сентябрь (№ 12) санында.)*



Аерым шәхес абруена сылтама, аудиториянең күпчелеге фикеренә таяну дәлилнең бер төре. Аудитория фикеренә таяну дәлилләре арасыннан гамәли әһәмияте, бурыч үтәүгә өндәү, зарурилык дәлилләрен дә аерып карыйлар.

Гамәли әһәмиятле дәлилләрдә теге яки бу фикерне сайлауның файдалыгына, кулайлыгына игътибар ителә. Мондый дәлилләрдән, Мәккә халкының Исламны кабул итүдән нинди файда күрәчәген аңлаткан аятьләрне әйтеп үтәргә кирәк: "Хактыр ки, сезгә шундый мәртәбәле бер Китап иңдердек: анда сезгә үгет-нәсыйхәт тә, шәрәфләр дә тупланган. Һаман шуны аңламыйсызмы?" ("Әнбия (Пәйгамбәрләр)" сүрәсенең 10 нчы аяте).

Аудитория хуплаган бурыч төшенчәсенә нигезләнгән дәлилләр бурычка тугрылыкны куәтләргә өндәгән дәлилләр булалар. Мәсәлән, Коръән иңдерелгәнче, мәҗүсиләр, аларга пәйгамбәр җибәрелгән очракта, Аллаһның кануннарын, яһүдләр һәм христианнарга караганда да, яхшырак үтәргә ант итәләр. Шул сәбәпле дә Мәккә халкын Исламга өндәү үзләренә йөкләгән бурычларын, вәгъдәләрен исләренә төшерү белән үрелеп бара: "(Мәккә мөшрикләре) Аллаһ исеме белән ант иттеләр:

- Валлаһи! Безгә дә кисәтүче пәйгамбәр килсә, башка халыкларга (яһүд белән христианнарга) караганда да без алданрак тугры юлга баскан булыр идек, - диделәр. Пәйгамбәрнең килүе аларның тугры юлдан ераклашуын арттырды гына" ("Фатыр (Яралтучы)" сүрәсенең 42 нче аяте).

Зарурилыкка дәлилләрдә тәкъдим ителгән чишелешнең кире каккысызлыгы аңлатыла. Мәсәлән: "Раббы алдында (җавап бирергә) тупланачакларын белгәннәрне шушының белән (Коръән белән) үгетлә, кисәт. Аларга ул вакытта Аллаһтан башка яклаучы дус булмас. Бәлки алар (акылга килеп) иман китерер, тәкъва булыр" ("Әнгам (Малтуар)" сүрәсенең 51 нче аяте).

Башка яклаучысы һәм ярлыкаучысы булмагач, ничек инде кешеләр Аллаһ юлыннан тайпыла алалар? Шундый дәлилләр ярдәмендә, Коръән, иманның зарурилыгын һәм Аллаһның кушканнарын үтәү тиешлеген исбатлый.

Коръәндә мәгънәви һәм хисси дәлилләр үзара үрелеп баралар. Шул сәбәпле, хис белән өретелеп тәэсирчәнлеге арткан мәгънәви дәлилләрнең исбатлау көче артып китә. Уйлап чыгарылган илаһларга табынуның мәгънәсез бер шөгыль булуы ни дәрәҗәдә үтемле аңлатылганын күзәтеп үтик: "Аллаһ төнне көн белән аралаштырыр, көнне исә төн эченә кертер. Кояш белән Айны үз әмере белән йөртер. Аларның һәрберсе билгеләнгән мөддәткә чаклы шулай йөрер. Боларның бөтенесен дә Аллаһ берүзе майтара. Барча милек - Аныкы, Аны инкяр итеп, сез табынган (потлар, сын)нар исә хәтта чикләвек кабыгындагы элпәнең бер җепселенә дә хуҗа була алмыйлар.

Әгәр дә сез аларны (дога кылып, Илаһка тиңләштергән сыннарыгызны, потларыгызны, һәйкәлләрегезне ярдәм сорап) чакырсагыз, алар сез чакырганны ишетмәс (догаларыгызны кабул итмәс). (Чөнки алар җансыз) ишеткән сураттә дә, сезгә җавап бирмәсләр (ярдәм итә алмаслар). Кыямәт көнне Аллаһка тиң булудан ваз кичәрләр (файда да, зыян да эшли алмаслар). Бу Хакыйкатьне сиңа барча нәрсәләрдән хәбәрле булган Аллаһтан башка һичкем әйтмәс" ("Фатыр (Яралтучы)" сүрәсенең 13-14 нче аятьләре).

Коръән Аллаһның бер үзенә табыну өстенлеген аңлатып кына калмыйча, шул ук вакытта тыңлаучыларда бу мәсьәләгә тиешле мөнәсәбәт тә оештыра. Акылында булган кеше бернинди дә кодрәткә ия булмаган һәм аның ялваруларына колак салмаган кемгәдер ярдәм сорап мөрәҗәгать итәрме икән? Мәгънәви дәлилләрнең үтемлелек чаралары белән хисси дәлилләрнең тәэсирчәнлек мөмкинлеге ярашу Коръән раслауларын анык һәм бәхәстән өстен итә.

Алда китерелгән мисалларда Коръәндәге дәлилләрнең исбатлаулардан тыш аралашу вазифасын үтәүләре дә аңлашыла. Алар ритор (вәгыйзь) белән аудиториянең аралашуын җиңеләйтәләр, карашлар берләшүгә ярдәм итәләр. Шул максатны күзаллап аудитория белән бәйләнеш урнаштыруда төрле сөйләм чаралары кулланыла да: мөрәҗәгатьләр, өндәмәләр, риторик эндәшләр, читләтеп һәм турыдан-туры сораулар, риторик сораулар һ. б. Мәсәлән, Кыямәт көнендә яңадан терелүнең хаклыгын раслаганда, Коръәни-Кәрим безне бәхәс алымына ияртә: "Кеше үзен: һич чикләүләрсез, авызлыксыз, күзәтүчесез яшәргә хаклы, дип саныймы әллә? Ул ана карынына атылган бер тамчыдан хасил икәнен онытамы? Соңра шул тамчы бер оешкан кан кебек (яралгы) булды, аннан соң аны кеше кыяфәтенә кертеп, дөньяга җаралттык. Ирле-хатынлы итеп тудырттык. Шушыларны бар итә алган Аллаһ мәетләрне генә терелтә ала торгандыр, шәт?" ("Кыямәт" сүрәсенең 36-40 нчы аятьләре).

Әлбәттә, күзгә бәрелеп торган хакыйкать белән килешкәндә, каршы сүз сөйләүчедә дә (оппонентта) танырга теләмәгән фикерләр белән ризалашу теләге туа.

Гомумиләштереп әйткәндә, Коръәндәге дәлилләр теге яки бу ышануларның, гамәлләрнең һәм әхлакый сыйфатларның дөреслеге яки ялгышлыгына инану чарасы буларак китерелгәннәр. Әлеге дәлилләрнең риторик кыйммәте Коръәни-Кәрим тезисларының хаклыгын нигезләп кенә калмыйча, кешенең рухи дөньясына сүз ярдәмендә уңай йогынты да ясыйлар. Изге Коръәннең аудиториясе Җир шарындагы берничә миллиард халыкны берләштерсә дә, төрледән-төрле карашлы, акыл-белем дәрәҗәсе төрле дәрәҗәдәге кешеләр аның дәлилләренең исбатланган булуын аңлыйлар.

Йомгаклап әйткәндә, тел-сурәт, сөйләм оештыру чараларының һәрьяктан камил җыелмасы Коръәни-Кәримнең тиңдәшсезлегенә тагын бер таныклык, тагын бер дәлил.

**Гаптрәүф НУРИЕВ,**
**филология фәннәре докторы**

## Хәнәфи мәзһәбендәге мөселманнарның хаж кылу тәртибе

*(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)*

изар дип атыйлар. Киемнең икенче өлеше - рида, аның белән җилкәне каплыйлар. Тегелгән кием кию тыела. Ләкин тегелгән башмаклар кияргә була. Тырнакларны кисү, мыекны кыру, култык астындагы, касыктагы төкләрне бетерү, баштагы чәчне алдыру - күркәм гамәл. Ихрамга кергәнче хушбуй сипсәң яхшы. Мөслим имам, мөэминнәрнең анасы Гайшәдән алып, шундый бер хәдисне китерә: "Пәйгамбәребез (сгв) ихрамга кергәндә үзе таба алганнар арасындагы иң яхшы хушбуйларын гына сөртә иде". Аннан соң хаҗга керүнең ике рәкагать сөннәт намазы укыла һәм күңелең белән хаҗ кылу ниятләнә. Һәм бу вакытта ният сүзләре әйтелә: "Аллаһүммә инниии үриидүл хәҗҗә фәйәсиирһү лии үә тәккабәлһү миннии" (Аллаһым, мин хаҗ кылырга ният иттем, аны кылуга миңа җиңеллекләр бир, һәм дә минем хаҗымны кабул кыл!). Аннан соң "Ләббәйкә" укыйлар. Әгәр дә таматтуг ысулы белән хаҗ кылына икән, башта гомрә кылу өчен ният әйтелә. "Ләббәйкә" сүзләре Пәйгамбәребездән (сгв) бирелгән, шуңа да, аны киметергә дә, үзеңнән нидер өстәргә дә кирәкми. "Ләббәйкә" укылмый торып, гәрчә ният кылынса да, бу хаҗ кылу йолаларына керү булып исәпләнми.

Ихрамга кергән мизгелдән башлап Аллаһы Тәгалә тыйган бар гамәлләрдән дә читләшеп торырга кирәк. Ир-хатын мөнәсәбәтләре, хәтта бу турыда хатының янында сүз кату да тыела. Төрле бәхәсләргә керү, кыргый җанварларны үтерү, аларның кайда булганнарын ихрамда булмаганнарга әйтү шулай ук тыела, тегелгән өс һәм баш киемнәре, хөффәләр (читекләр) кияргә; йөзне һәм башны капларга, тәнгә һәм киемгә хушбуй сөртергә, баштагы чәч бөртекләрен, биттән һәм тәннән төкләрне алып ташларга, тырнак кисәргә, башны һәм сакалны сабын белән юарга ярамый. Су коенырга һәм киемнәрне юарга, өй, чатыр, зонт, паланкин күләгәсендә булырга рөхсәт ителә. Каеш белән билне буарга ярый.

"Ләббәйкә"не мөмкин кадәр күбрәк, бигрәк тә вакыт алмашынган саен укырга кирәк. Басып торганда да, утырып торганда да, ятып торганда да, караңгы төшкәндә дә, таң атканда да, калкулыкка күтәрелгәндә дә, аннан төшкән вакытта да, йоклап киткәндә дә, уянганда да, намаз укыгач та "Ләббәйкә"не укырга кирәк. Кыскасы, намаз укымаган һәм вирд башкарылмаган һәр вакытта да, бар җирдә дә "Ләббәйкә" укырга кирәк.

***"Әл-Лубаб фи Шәрхел-Китаб"тан***

# Ходай Үзе көч бирә

## *(Хаҗ кылу - һәр мөселман өчен фарыз гамәл)*

**Райондашларыбыз хаҗ сәфәреннән кайтып, алар белән очрашулар үткәрә башлагач, әби-бабайлардан: "Минем дә барасым килгән иде. Картайдым шул инде. Хаҗ гамәлләрен үти алмам, кан басымым уйнап егылырмын, көчем җитмәс, дип куркам", - дигән сүзләр ишеткәләргә туры килде.**

Климат алышыну кешегә шул дәрәҗәдә нык тәэсир итә микән соң? Сәламәтлекләре бик нык булганнар гына хаҗ сәфәренә чыга аламы? Укытучым, Мамадыш районының Урта Кирмән абыстае Рәшидә Әүхәдиева кунакханәдән чыккач, кабат аны тиз генә таба алмавын, эзләгәндә полиция егетләренең үзен гел коляскага утыртып йөрүләрен сөйләгән иде. Республикага яхшы мәгълүм шәхес озак еллар колхоз рәисе булган Фазылҗан Мөхәммәтҗанов белән дә хаҗ сәфәре турында озаклап әңгәмә корганым булды.

- Күп кеше бит беренче чиратта самолётта очудан курка. Кан басымым күтәрелер, ди. Андый нәрсә хәзер бөтенләй юк. Безнең төркем Казаннан очып киткән иде. Кузгалып киткәнне дә сизмәдек. Сәгать ярымнан беренче тапкыр ашаталар. Поднос белән сиңа җиде-сигез төрле ризык китерәләр. Утыргычлар бик иркен. Кәнәфидә икешәр кеше генә утыра. Каршыда телевизор тора. Сәгать ярым узгач тагын ашаттылар. Самолёттагы хезмәткәрләр бик әдәпле, тәмле телле. Бөтен сорауларыңа җавап бирәләр, - дип сөйләде ул. - Истанбулда икенче самолетка күчеп утырып Мәккәгә өч сәгать очтык. Анда да җаның теләгән ризыкны сайлап алып тәгам җыясың. Юлда барганда хәзрәтләр көн саен икешәр вәгазь сөйләп күңелләрне рухландырып тордылар. Мәккәгә барып төшкәч тә алар Кәгъбәтулланы әйләнергә, тәваф кылырга алып китте. Аны җиде тапкыр әйләнәсең. Бер әйләнү - дүрт йөз метр. Димәк, барысы ике километр сигез йөз метрга тула. Анда кеше бик күп була, әмма бер-береңә комачаулык итү юк. Ялгыш кына берәрсенә орынып китеп борылсаң да, ул кеше үзе синнән гафу үтенә. Кешеләр бик тә әдәпле, тәртипле. Аннан ике тау арасына алып китәләр. Алар арасыннан чишмә чыга. Аның суын зәм-зәм суы диләр. Кешеләр хаҗдан башка вакытта да анда килеп дәваланып китә икән. Суы тешләрне өшетерлек суык, көн кызу булса да, тамак төбенә салкын тими. Җиде йөз метрны җиде тапкыр әйләнәсең. Барысы 4900 метрга тула бит. Аларны әйләнгәндә бер урынны - 70-80 метрны - йөгереп үтәргә кирәк. Анда армыйсың да. Гәүдәңдә үзгә җиңеллек, рухи күтәренкелек тоясың. Авыру кешеләр дә йөгерә башлый. Бөтенләй йөри алмаган, аяксыз кешеләрне коляскага утыртып йөртәләр. Анда башыңда дөньяви фикерләр бөтенләй калмый. Аллаһы Тәгаләгә, дингә бик якынаясың. Самолётта очканда ике көн йокламаган идем. Арганлыкны бөтенләй сизмәдем дә. Мәккәдә палаткаларда, Мәдинәдә кунакханәдә яшәдек. Икесендә дә бик җайлы. Ризыкларны алып килеп ашаталар. Күп кеше анда кызудыр дип, курка. Кояш кыздыруы бөтенләй сизелми. Таш атарга көндез барсаң, кояштан капланырга зонт бирәләр. Үзең бара алмасаң, җиде ташыңны кешегә биреп җибәрергә дә була. Өч километр чамасы барасы, бер чыккач, бер авырлыгы да юк. Мәккә мәчетенең территориясе безнең Кече Соннан аз гына бәләкәйрәк. Мәдинә мәчете әйләнә-тирәсенә колонналар кебек өч рәт баганалар утырткannar. Көндез аның әйләнә-тирәсе зонтлар белән каплап алына. Урамнар бик чиста. Шырпы кисәге дә таба алмыйсың. Тәртип яхшы. Полиция кешеләре күзгә дә чалынмый анда. Ашату яхшы, ризыклар 12-13 төрле, телефоннан сөйләшергә үзләренең сим-карталарын бирәләр. Теләгән кешегә куркасы түгел икән. Җәмәгатем Корбанбикә дә йөри алмам, дип бармаган иде. Алып бармаганыма үкенәм хәзер.

Яхшылык эшлә дә суга сал, халык белмәсә балык белер, дигән әйтем дә бар бит. Озын гомер юлларында кылынган яхшылыклар кешегә барыбер кире әйләнеп кайта. Фазылҗан абый белән дә Казан аэропортында бер ир килеп күрешә. Усалидә колхоз рәисе булган чакта хуҗалык стипендиаты итеп укыткан булган икән. Актаныш районының Вахитов исемендәге совхозында директор булган. Хәзер крестьян-фермер хуҗалыгын җитәкли. Кире Казанга кайтып җиткәнче гел ярдәм итеп, булышып йөрде, ди Фазылҗан абый.

Хаҗга барырга өлгерермен әле, дип карарга кирәкми. Вакыт көтеп тормый ул. Күңелең белән тәвәккәлләргә кирәк.

**Минневәрис**
**МИНГАЛИЕВ**

# Ислам Совет дәүләте сәясәтендә (1943-1948 еллар)

*(Ахыры. Башы 2 нче биттә.)*

СССР Министрлар Советының 1946 елның 3 декабрендә кабул ителгән "Дин эшлеклеләренә салым салу тәртибе" махсус карары буенча дин эшлеклеләренә салым күләме киметелә. 1948 елның августында алар өчен паспорт режимы да йомшартыла. Дәүләт-дин мөнәсәбәтләрен нормальләштерүдә СССР Халык комиссарлары Советының 1946 елның 28 гыйнварында кабул ителгән "Дини оешмаларның гыйбадәт йортлары турында"гы карары әһәмиятле роль уйный. Бу карарның беренче пунктында: "Дини җәмгыятьләр файдалануында булган гыйбадәт биналарын, бар диндәгеләр өчен дә, алар гыйбадәт кылу өчен арендага алган йортларны СССР Халык комиссарлары Советы каршындагы Дини эшләр Советы рөхсәтеннән башка ябу тыела", диелә. Бу - элеккеге дини мәхәлләләрне торгызырга рөхсәт итү буларак кабул ителә.

СССР Халык комиссарлары Советы каршындагы Дин эшләре буенча Совет һәм аның өлкә-республикалардагы вәкилләре гыйбадәт йортларын ачу, дини мәхәлләләр оештыру турындагы дини төркемнәрнең гаризаларын тикшерергә керешәләр. Гамәлдә исә бу яңадан теркәүгә кайтып кала.

Мәсәлән, 1945 елның 1 гыйнварына БАССРда унике мәчет теркәлә. Аларның өчесендә бернинди дин эшлеклесе дә булмый.

Дин тотучыларның бу гаризаларын тикшергәндә СССР Министрлар Советы каршындагы Дин эшләре буенча Советның 1947 елның гыйнварында таратылган "Гыйбадәт йортлары ачу турындагы эшләрне рәсмиләштерү" дип аталган хатка таянып эшләргә кирәк була. Тутырылырга тиешле документлар исемлеге мәчетләр ачу мәсьәләсен уңай хәл итүне шактый кыенлаштыра. Күрсәтмәләрдә, "яңа вак дини оешмалар саны артуын булдырмау өчен", гаризаларны кире кагу тәртибе дә әйтеп кителә: бинаның яраксыз, төркемнең аз санлы булуы, бинаның мәдәният, сәнәгать-оборона яки торак максатларында файдалануы, якында гына бу конфессиянең гыйбадәт йорты булуы һ. б.

Хакимият органнарының гыйбадәт йортларын ачтыру, мәхәлләләр төзү турындагы гаризаларны кире кагу өчен бар нигезләре дә була. Мәсәлән, Стәрлетамактагы дүрт мөселман мәхәлләсенең шәһәрдәге Кырым урамы, 33 нче йортта мәчет ачу турындагы гаризасын, элек мәчет булган ул йортның балалар бакчасына әйләндерелүе, хәзерге Башкортстанның Бүздәк районындагы Гафури (элекке исеме - Чукраклы) авылы мөселманнарының гаризасын "җиде километр ераклыктагы күрше Иске Муса авылында мәчет булуы" сәбәпле кире кагалар.

Иң күп үтенечләр 1945-1946 елларда канәгатьләндерелә. Сугыш бетүе хакимияткә дингә карата булган элеккеге лояль мөнәсәбәттән баш тартырга мөмкинлек бирә. Партиянең идеологик эшне көчәйтү турындагы 1946 елгы карары 180 градуска кире борылуны, барлык башкача фикер йөртүчеләргә, аеруча дин тотучыларга карата, элеккеге килешүләрсез басым ясауга күчүне аңлата. Идел буенда, Уралда, Мордовиядә дини җәмгыятьләрне теркәү күпкә кими.

1947, 1948, 1949 елларда мәхәлләләрне теркәү кискен кими. 1948 елның апрелендә үк инде Дин эшләре буенча Совет үзенең җирле вәкилләренә "дини җәмгыятьләрне теркәүне туктатырга катгый рәвештә тәкъдим ителүе" турында күрсәтмәләр җибәрә. 1950-1954 елларда Дин эшләре буенча Совет рәхимсез карашларда тора: дин тотучыларның бер генә үтенече дә канәгатьләндерелми.

Шунысын да искәртеп үтәргә кирәк: Дин эшләре буенча Советта бары тик тиешле бар документлары булган гаризалар гына тикшерелә, канәгатьләндерелә яки кире кагыла. Гаризаларның күп өлеше документларның тиешле дәрәҗәдә тутырылмаган булуы сәбәпле түбәндәге идарә баскычларында ук кире кагыла.

Мәләвез мөселманнарының тырышлыклары бары тик дүртенче омтылышта гына уңышка ирешә. Стәрлетамак районының Аллагуват авылы дин тотучыларның гаризалары 1946 елдан 1955 елга кадәр карала. Кайвакыт дин тотучылар Югары Советка шикаять белән мөрәҗәгать итәргә - "Булганин исеменә" хат язарга мәҗбүр булалар.

Шуңа да карамастан, мөселманнар элеккечә үк дини гореф-гадәтләрне башкаруын дәвам иттерә, балаларга исем кушканда, туйлар вакытында, мәрхүмнәрне җирләгәндә дини йолалар үтиләр, һәм дә әлбәттә, мәчетләргә һәм муллаларга мохтаҗлык кичерәләр. Дин эшләре буенча Совет вәкиле отчётларында: хакимият органнары рөхсәтеннән башка дини йолаларны башкаручы дини төркемнәр "теркәлмәгән дини җәмгыятьләр" булып исәптә торалар, диелә. Мондый статус мөселманнарга җәмгыятьнең тиешле гыйбадәт-йолаларында катнаша алу гына түгел, ә бәлки, мөэминнәрнең төп бурычы - мәхәллә, мәчет тоту өчен акча җыярга да мөмкинлек бирмәгән.

Шулай да, кайберәүләр артта калган, надан бабайлар дип атаган дин эшлеклеләре, бернигә дә карамастан, төрле репрессияләр, кимсетелүләргә дә түзеп, еш кына, яшерен рәвештә дә, Аллаһы Тәгалә күрсәтмәләрен таратканнар һәм башкарганнар. Традицион исламга төрлечә пычрак атарга тырышкан, шул исәптән аны "бабайлар исламы" дип атаган бүгенге күпме "активистлар" шундый сынаулар астында калса, аны ничек кичерер иде микән?

***Марат хәзрәт МӘРДАНШИН,***
***тарих фәннәре кандидаты,***
***ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Голамәләр шурасы әгъзасы***

# Балалар диндә тәрбияләнә

**Елдан-ел мөселманнар саны арта, мәчетләрдә намаз рәтләре ишәя, мәдрәсәләрдә укучылар күбәя. Яшьләрнең дингә килүе аеруча куандыра. Алар матур гаиләләр кора, тәүфыйклы балалар тәрбияли. Һәркемгә мәгълүм: балалар - безнең киләчәгебез. Аларга нинди тәрбия бирсәк, нинди гамәлләргә өйрәтсәк, илебезнең, халкыбызның киләчәге дә шундый булыр.**

Азнакай мөхтәсибәте дә балаларга, аларның ата-аналары белән берлектә, дөрес дини тәрбия, гыйлем бирүдә, балаларны илебезгә, җәмгыятькә файда китерүче шәхесләр итеп тәрбияләүдә эш алып бара.

Балалар мәдрәсәсе Зәңгәр мәчеттә инде өч ел дәвамында эшләп килә. Гөлшат һәм Гайшә ханымнар балаларга һәр якшәмбе ислам дине нигезләрен, пәйгамбәрләр тарихын, гарәп телен, Коръән, намаз укырга өйрәтә. Мәдрәсәдә төрле чаралар уза: Әлифба бәйрәме, Сабантуй, Намаз һәм Коръән уку бәйгеләре... Мәдрәсәгә 7-16 яшьлек балалар йөри. Быел да монда белем алырга теләүче кызлар һәм малайлар әниләре, әбиләре, апалары белән Зәңгәр мәчеткә килә ала. Укулар 1 октябрьдән башлана.

Мәдрәсәдә укучы балалар республикакүләм чараларда да катнашып, призлы урыннар ала. Мәсәлән, быел 6 нчы мәктәп укучысы Фәйрүзә Әминова Чаллыда узган республикакүләм Коръән уку бәйгесендә III урынга лаек булды һәм Болгарда яшьләр өчен оештырылган мөселман лагеренда ял итте.

Балалар өчен бәйрәмнәрне мөхтәсибәтебез шәһәр күләмендә дә уздыра: Ураза гаете Яңа Юл мәчете ихатасында спорт чарасы буларак инде өченче ел оештырыла. Былтыр Корбан гаетендә Яшьләр үзәгендә театральләшкән тамаша күрсәтелде, балалар үзләре дә чыгыш ясады. Февральдә шунда ук "Кышкы уеннар" узды, Пәйгамбәребезнең (сгв) хәдисенә нигезләнеп төшерелгән "Мәрхәмәтлек" дигән мультфильм күрсәтелде. Җәен Әсәйдә мәселман Сабан туе, Тарсус паркында балалар өчен Сабантуй оештырдык. Бәйрәмнәргә килгән балаларның берсе дә бүләксез китми. Гомумән, эшмәкәрләребез һәр чарада матди ярдәм күрсәтә.

Җәен балаларның ялын оештыруда да мөхтәсибәт читтә калмый. Һәр ел мөселман лагере йөзгә якын баланы җыя. Мәскәүдән, Казаннан, башка шәһәрләрдән әби-бабайлары янына җәйге ялга кайткан балалар да, үзебезнекеләр дә Ак мәчет каршындагы лагерьга бик теләп йөри. Алар анда дин сабаклары өйрәнә, төрле конкурслар, спорт чараларында күңел ача, экскурсиягә йөри, әхлак тәрбиясе ала. Лагерьда балалар белән мәдрәсәдә гыйлем алучы яшьләр эшли: кызлар өчен Алсу ханым җаваплы, аңа ярдәмгә Урыссу посёлогындагы "Фәнис" мәдрәсәсендә укучы Диана белән Энҗе кайта. Малайларны да "Фәнис" мәдрәсәсендә укучы егетләр тәрбияли. Яшьләребез өчен бу үзенә күрә бер тормыш тәҗрибәсе, алар шул рәвешле җәйге практикаларын да үтә.

Авылларда да балаларга дини белем, тәрбия бирү өлкәсендә эш алып барыла. Һәр ел эшләп килүче Әсәйдәге җәйге лагерьда Илгизә абыстай укыта. Урсайда Фәнзия ханым дәресләренә уннан артык бала йөри. Алар шәһәребездә узучы бер чараны да калдырмый, төркемнәре белән килеп, рәхәтләнеп бәйгеләрдә катнаша, призлы урыннар ала. Быел Кәкре Елга авылында да беренче тапкыр лагерь оештырылды. Анда 25 бала ял итте. Ялны Фәһим хәзрәт белән Гүзәл ханым оештырды.

***Айгөл ШӘРИПОВА,***
***Азнакай***




## Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| *Шимбә* | 29.09.12 | 5:13 | 6:43 | 13:02 | 16:36 | 18:23 | 19:53 |
| *Якшәмбе* | 30.09.12 | 5:15 | 6:45 | 13:02 | 16:35 | 18:21 | 19:51 |
| *Дүшәмбе* | 1.10.12 | 5:17 | 6:47 | 13:02 | 16:33 | 18:18 | 19:48 |
| *Сишәмбе* | 2.10.12 | 5:19 | 6:49 | 13:02 | 16:31 | 18:15 | 19:45 |
| *Чәршәмбе* | 3.10.12 | 5:21 | 6:51 | 13:02 | 16:29 | 18:13 | 19:43 |
| *Пәнҗешәмбе* | 4.10.12 | 5:23 | 6:53 | 13:02 | 16:27 | 18:10 | 19:40 |
| *Җомга* | 5.10.12 | 5:25 | 6:55 | 13:02 | 16:26 | 18:08 | 19:38 |
| *Шимбә* | 6.10.12 | 5:27 | 6:57 | 13:02 | 16:24 | 18:05 | 19:35 |

# Авыл хуҗалыгы ярминкәләрендә "Хәләл" стандартлары комитеты таныклыгына ия булган предприятиеләр дә катнаша

**Атна саен Казан һәм Чаллы базарларында авыл хуҗалыгы ярминкәләре оештырыла.**

Шул уңайдан, ТР мөселманнары Диния нәзарәте каршындагы "Хәләл" стандарты комитеты җитәкчесе Марат Низамов әлеге ярминкәләр хакында: "Атна саен үткәрелә торган ярминкәләр шәһәр халкы өчен бик уңай: республикада үскән сыйфатлы продукцияне кулай бәядән алырга мөмкинлек бирә. Ярминкәдә катнашучылар арасында безнең комитет белән күптәннән эшләп килә торганнары да бар. Аларның продукциясе сыйфатлы һәм тикшерелгән, шуңа да сатып алучылар "Хәләл" комитетының тамгасы булган продукцияләрнең сыйфатында икеләнмәсеннәр", - диде.

"Хәләл" стандарты комитетының таныклыгына ия булган предприятиеләр арасында республикада казылык, ярымфабрикат һәм деликатеслар җитештерү белән танылган Казан ит комбинатын атарга кирәк. Шулай ук кош ите, казылык, деликатеслар җитештерүче "Чаллы-бройлер" ширкәте һәм кондитерлык эшләнмәләрен җитештерү белән танылган "Чаллы-икмәк" компаниясе дә бар.

"Хәләл" стандарты комитеты тарафыннан тикшерү узган һәм махсус таныклыкка ия булган предприятиеләр исемлеге белән www.halalrt.com сайтында танышырга мөмкин.

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. № 13 (156) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** 9418.
**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 27 сентябрь көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.
Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан саклангыз!**